ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 апрель 2026ел № 4153

Башкарма комитетның 2024 елның 22 октябрендәге 6968 номерлы Карары белән расланган «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2024 елның 22 октябрендәге 6968 номерлы Карары белән расланган «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 пунктта чараның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар кызы» муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (1-4 сыйныфлар)»;

2) 53 пунктта «Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум» графасының «2026», «2027» баганаларында «50,0» цифрын «25,0» цифрына алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлектәге 55 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «55. «Татар кызы» муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (5-8 сыйныфлар) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 0 | 55 | 55 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 0 | 25,0 | 25,0 | Мәктәп яшендәге балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү». |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов